ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УСЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

423739, Качкын авылы,
Үзәк ур.,37/в нче йорт.
Тел/факс 3-44-63

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423739, д. Качкиново,
ул.Центральная, дом 37/в.
Тел/факс 3-44-63.

КАРАР

13.12.2019г. №22

Салют үткәрү урыннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 313-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 2 декабрендәге 886 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында " Карарын үтәү максатларында, карар бирәм:

1. 2019 нчы елның 15 нче декабреннән 2020 нче елның 15 нче гыйнварына кадәр Усы авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим урнаштырырга.
2. Пиротехник эшләнмәләр кулланып салют үткәрү урыны буларак билгеләргә, торак объектларына кадәр ераклык билгеләнгән таләпләргә туры килә
   а) «Эреш» чишмәсенә юл буйлап Баҗана елгасыннан көньяк-көнчыгыш якка таба 30м.;
   б) Усы авылына М-7 ягыннан кергәндә, ындыр табагы һәм КФХ "Нурлыев Ф.Ф."ның МТП арасындагы аланда
3. Янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләрне куллану тыелган объектлар исемлеген раслау (1нче кушымта)
4. Яңа ел салюты үткәрүне оештыручылар административ законнар нигезендә җаваплы.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Усы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе: З.З.Ахмаев

Усы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
Карарына кушымта №1

Янгынга каршы режим гамәлдә булган чорда пиротехник эшләнмәләрне куллану тыелган объектлар исемлеге:

1. Сәнәгать объектлары: төзелеш сәнәгате оешмалары.

2. Торак-коммуналь хуҗалык объектлары:
Торак фонды, халыкны газ, җылылык һәм электр белән тәэмин итү объектлары.

3. Авыл хуҗалыгы объектлары:
Терлек асраучы хуҗалыклар; ашлык саклау складлары; агу химикатлары һәм минераль ашламалар саклау складлары; орлык эшкәртү һәм агулау предприятиеләре; азык әзерләү цехлары; ремонт, технологик хезмәт күрсәтү һәм саклау гаражлары һәм парклары; матди складлар.

4. Кешеләр күп була торган объектлар:
Дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының административ биналары, мәдәният, спорт, мәгариф, сәламәтлек саклау объектлары, кибетләр.